Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2020 елның 25 сентябре 5№

Әлки муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым оешма хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында

Әлки муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым оешма хезмәткәрләргә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге «Әлки муниципаль районы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым оешма хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»148 номерлы карары белән билгеләнгән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә, хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар җитәкчесе, белгече һәм хезмәткәренә айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән арттырырга.

2. Бюджет даирәсендә эшләүче Бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәплэп чыгару өчен әлеге Карарның 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлекләрдә бюджет даирәсен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаучы аерым оештыру структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин